**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Первомайская ул., д.39, г. Лаишево, 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

Беренче май ур., 39 нчы йорт, Лаеш ш., 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

**2025 елның «08» декабре** **32-РС номер**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы уставы белән, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» һәм норматив-хокукый актларны туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын раслау турында» 2021 елның 1 февралендәге 3-РС номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын раслау турында» 2023 елның 31 июлендәге 77-РС номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын раслау турында» 2025 елның 17 мартындагы 13-РС номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2024 елның 08 июлендәге 53-РС номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертүне раслау турында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2022 елның 07 сентябрендәге 65-РС номерлы карары белән расланган карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2023 елның 31 гыйнварындагы 18-РС номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарны «Камская новь» район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб—адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

7. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп тору Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.П. Шитовка йөкләнә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**